***Мәктәп туры***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 44**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) утырдык
   ә) шунда
   б) шикелле
   в) ашаганчы

2. ***Кагыйдә*** сүзенең беренче авазына туры килә торган характеристиканы билгеләгез. **(2 балл)**
   а) шаулы, саңгырау, яңгырау пары [ғ], кече тел, авыз тартыгы
   ә) шаулы, яңгырау, саңгырау пары [г], тел арты, борын тартыгы
   б) шаулы, саңгырау, яңгырау пары [ғ], тел арты, авыз тартыгы
   в) шаулы, саңгырау, яңгырау пары [г], кече тел, борын тартыгы

3. Бирелгән фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Җилләр исү***
   а) авырый башлау
   ә) күп эш башкару
   б) берәр әйбернең кинәт юкка чыгуы
   в) гел ялган сөйләү

4. Сүз ясагыч кушымчаны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) -ның/-нең
   ә) -рак/-рәк
   б) -са/-сә
   в) -сыз/-сез

5. Җөмләдәге тартым белән төрләнгән исемнәрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Филнең – теше, боланның башы кыйммәт.* (Мәкаль)
   а) 2
   ә) 3
   б) 4
   в) 1

6. Җөмләдәге затланышлы фигыльләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Балачактан өйрәнмәсәң, картайгач үкенерсең.* (Мәкаль)

а) 1
ә) 2
б) 3
в) 4

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Зур фил дә* ***тычканнан*** *курка.* (Мәкаль)

а) ия
ә) урын хәле
б) аергыч
в) тәмамлык

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Фил күтәрмәгәнне тел күтәрә.* (Мәкаль)

а) иярчен ия җөмлә
ә) иярчен хәбәр җөмлә
б) иярчен тәмамлык җөмлә
в) иярчен аергыч җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган авазны һәм сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

__________ – сөйләмнең ритмик-мелодик ягы. [ __ ] – тел уртасы тартыгы. Сузык авазга беткән иҗек __________ иҗек дип атала. Һәрвакыт үзара антоним булган сүзләр __________ антонимнар була. __________ төшеп калса, сан исемләшә һәм сан, тартым, килеш белән төрләнә башлый. Җөмләнең мәгънәсе аңлашылсын өчен кирәк булган җөмлә кисәкләре барысы да кулланылса, ул __________ җөмлә була.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

*дыхание* – __________ *полынь* –__________
*гостинец* – __________ *берег* – __________
*пыль* – __________ *лебедь* – __________

2. “Туган тел (татар теле) дәресендә” дигән темага 12 җөмләдән торган инша языгыз. **(16 балл)**